**ГЛАВА АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 22 нче йорт
Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

КАРАР
28 нче июнь 2026 ел

КАРАР
№ 2

## Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Уставының 19 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. ТР, Яңа Чишмә районы, Акъяр авылы, Ленин җир кишәрлеге 1б адресы буенча урнашкан 16:31:080103:427 кадастр номерлы, 1000 кв. м. мәйданлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча 2026 елның 20 июленә 17.00 сәгатькә ачык тыңлаулар билгеләргә. Уздыру урыны: Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе кабинетын Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акъяр авылы, Совет ур., 22нче йорт.

2. Гавами тыңлаулар күрсәтелгән көнне 17.00 сәгатьтә уздырылуын билгеләргә., гавами тыңлаулар уздыру урыны – Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акъяр авылы, Совет ур., 22 йорт адресы буенча Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Кабинеты.

3. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануны үзгәртү мәсьәләсен исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Садретдинов Дамир Илнар улы – Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Минабетдинова Рәсимә Галимҗан кызы-Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе, эшче төркем сәркатибе;

Шәйхетдинова Ризифа Нәбиулла кызы – Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры, комиссия әгъзасы.

4. Шуны билгеләргә::

а) Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләр проект буенча фикер алышуда әлеге карар белән билгеләнгән гавами тыңлауларда катнашу юлы белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясында һәм Акъяр авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә катнашалар;

б) гавами тыңлауларга әзерлек барышында гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә буенча Акъяр җирлегендә яшәүчеләрнең язма тәкъдимнәрен кабул итү, карау һәм исәпкә алу алып барыла;

в) Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең чыгарылган сорау буенча язма тәкъдимнәре («гавами тыңлауларга» тамгасы белән) 2026 елның 20 июленә кадәр эш көннәрендә 08.00

сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Акъяр авылы, Совет ур., 22 йорт.

Тәкъдимнәр шулай ук Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан почта аша күрсәтелгән адрес буенча җибәрелергә мөмкин.

г) Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча язма тәкъдимнәрен алдан караганда эшче төркем гавами тыңлаулар барышында каралырга тиешле мәсьәләләр арасыннан төшереп калдыралар:

- аноним тәкъдимнәр;
- әлеге карар нигезендә гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләгә кагылышлы булмаган тәкъдимнәр;
- 17.00 сәгатьтән соң килгән тәкъдимнәр 2026 елның 20 июле.

5. Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларда катнашу теләге турындагы гаризалары (кызыксынган затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урынын, шәхесен таныклаучы документның төрен, сериясен һәм номерын күрсәтеп) 2026 елның 20 июленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә дип билгеләргә: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Акъяр авылы, Советская, д.22.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы — Д.И. Садретдинов